Тугызынчы февральдә Мордовия, илебезнен башка регионнары белән берләштән, 37-нче «Лыжня России» дигән ботенроссия массакvләм чангы юлы ярышларында катнашты. Саранскта бу бәйге инде унбишенче тапкыр vткәрелә.
«Лыжня России» Мордовиянен башкаласы Саранск шәһәрендә генә тvгел (2300 кешегә якын катнашучы иде), республикабызнын башка районнарында да чангы ярышларында 1800 мен кеше катнаштылар.
Кышкы тор спорт ярышларында аны яратучылар белән бергә профессиональ спортсменнар, спорт ветераннары, сәясәт һәм хокvмәт эшлеклеләре һәм шулай ук хезмәт коллективлары ярышты.

37-нче «Лыжня России» дигән ботенроссия массакvләм чангы юлы ярышларында Саранск ишетv буенча кимчелекләре булган мәктәп-интернаттан ун укучы белән дvрт педагог катнашты. Алар арасында егерме сигез ел бу уку йортындагы укучыларга белем биргән Роза Мухаметжан кызы Абсалямова *(фотода - сулдан дvртенче)* иде. Ул 27 ел чангы ярышларында катнаша һәм укучыларында да бу спорт торенә мәхәббәт тәрбияли. Призлы урыннар да яулаганы бар.
«Лыжня России» ярышында катнашучыларны Саранск шәһәре Главасы, оештыру комитеты рәисе П.Н.Тултаев, Мордовиянен спорт министры беренче урынбасары В.Ф.Учайкин һәм башкалар котладылар. Чыгышларында «Лыжня России» республикабызнын торле яшьтәге, торле милләт һәм торле дин кешеләрен берләштерvче чара булып торуын әйттеләр.
Бу конне жинелvчеләр дә булды, әмма барлык катнашучылар рәхәтләнеп чангыда шуып, кvтәренке кәеф белән ойләренә таралыштылар. Фиништан сон теләге булган һәркем кайнар чәй дә эчә, итле карабодай боткасы да ашый алды. Ярышта катнашулар очен кvнел ачу программалары да каралган иде.

Наилэ Насырова